**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Ялкын авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Гурьевка торак пунктында
2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2025 елның 23 октябреннән** **№ 2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33 номерлы Федераль законның 57 статьясына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Ялкын авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Гурьевка торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ**:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Ялкын авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Гурьевка торак пунктында (торак пункты территориясының өлешендә) яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан, МХО да катнашучылардан тыш.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

-торак пункт территориясен төзекләндерү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Ялкын авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Ялкын авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://

alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Ялкын авыл җирлеге Башлыгы** ____________ **И.В.Гущина**
(имза) (имзаның расшифровкасы)